МИНИСТЕРСТВО
ЗДРАВООХРАНЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**_________24.06.2026_________** г. Казань **№ _______1465__________**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2023 елның 28 ноябрендәге 2844 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указына туры китереп боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2023 елның 28 ноябрендәге 2844 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2024 елның 26 августындагы 1965 номерлы, 2026 елның 5 мартындагы 449 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр

каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә, комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе әлеге боерык белән раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министр урынбасары (комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (комиссия секретаре), Министрлыкның кадрлар бүлегенең, юридик бүлегенең, башка бүлекчәләренең министр тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;»;

Нигезләмәнең 2.4 пунктының икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук керемнәре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3.11 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;»;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенең күрсәтелгән боерык белән расланган составын яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Е.В.Демьянова

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
28.11.2023 елның 2844-нче номерлы
боерыгы белән
(24.06.2026 № 1465
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы редакциясендә)
расланган

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Сибгатов Илнур Заһит улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Фатихов Илдар Разин улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |

Комиссия секретаре:

| | |
|---|---|
| Фәхретдинов Марат Хәмзә улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Жирнова Галина Ивановна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» Федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең оештыру эше бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |

Зиатдинов Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Илдар бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык идарәсе башлыгы урынбасары- Фәрит улы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш
хисапчы урынбасары

Максимов «Казан дәүләт медицина университеты» Федераль дәүләт автоном
Игорь югары белем бирү учреждениесенең биомедэтика, медицина
Леонидович хокукы һәм медицина тарихы кафедрасы доценты (килешү буенча)

Мәхмүтов Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Чыңгыз иҗтимагый совет рәисе, «ЗА РОССИЮ «ХАЛЫК ФРОНТЫ»
Усман улы Гомумрәсәй иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы
төбәк бүлеге штабы әгъзасы (килешү буенча)

Нәкыйпова Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Гөлнара кадрлар бүлеге башлыгы
Рафаэль кызы

Пологов Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Артур фармация идарәсе башлыгы
Олегович

Сәгъдиева Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Елена медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын тикшереп
Тәлгать кызы тору идарәсе башлыгы

Саттарова Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Ләйсән икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсенең мәҗбүри медицина
Самат кызы иминияте чаралары буенча икътисадый анализ бүлеге башлыгы

Фролов Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
Дмитрий лицензияләү идарәсе башлыгы
Николаевич

Шрша Татарстан Республикасы Рәисе идарәсенең коррупциягә каршы

| | |
|---|---|
| Равия<br>Бәдертдин кызы | сәясәт мәсьәләләре буенча вәкиле (килешү буенча) |
| Яруллина<br>Эльмира<br>Равил кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы |